ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.04.2021 ел Баулы шәһәре №60

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга
бирелә торган социаль түләүләр
күләмен исәпләү өчен 2021 елның
II кварталына Баулы муниципаль
районында бер квадрат метр бәясенең
нормасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 мартындагы «Бәяләү эшчәнлегенә бәйле социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) тәртибен раслау турында» карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларында 2021 елның II кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 94 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НП эксперт-консультация советының Баулы шәһәрендә һәм Баулы районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен 2021 елның II кварталына билгеләү буенча тикшеренүләре нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2021 елның икенче кварталына Баулы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының хакын нормативын 27 682 (егерме җиде мең алты йөз сиксән ике) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинга йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров